**Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Советы**

## КАРАР

09 июнь 2021 № 10

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, тикшерү һәм карау Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берлеге Уставының 15.1- статьяларына таянып, Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, тикшерү һәм карау Тәртибен кушымтада бирелгән тәртиптә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек Башлыгы: И.Х.Минегалиев

СОВЕТ БАЙЛАНГАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЙЛАНГАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607752814
ИНН 1623001621

Кукмара муниципаль районы
Байлангар авыл җирлеге Советының
2021 елның 09 июненең 10
номерлы Карарына кушымта

**Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, тикшерү һәм карау**
**ТӘРТИБЕ**

**1** бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

**1 статья Әлеге Тәртипне җайга салу предметы**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Байлангар муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә инициативалы проектларны тәкъдим итүгә, кертүгә, фикер алышуга, карауга, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуга бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен күрсәтелә торган инициативалы проектларны тәкъдим итү, тикшерү, карау һәм сайлап алу белән бәйле мөнәсәбәтләргә әлеге Тәртипнең нигезләмәләре, әгәр Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты белән һәм алар нигезендә кабул ителгән Байлангар авыл Советы карарларында башкасы каралмаган булса, файдаланылмый.

**2 статья. Инициативалы проектлар**

1. Инициативалы проект дигәндә әлеге Тәртиптә Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге яисә аның өлешендә яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру турында тәкъдиме аңлашыла.

2. инициативалы проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү;

5) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырыла торган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен файдалану күздә тотылган очракта, Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегенең бюджет чаралары күләменә күрсәтү;

8) Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге территориясенә яисә аның чикләрендә инициативалы проект гамәлгә ашырылачак өлешен әлеге Тәртипнең 3 статьясы нигезендә күрсәтү;

3. инициативалы проект әлеге статьяның 2 өлешендә каралган белешмәләре булган проектны тасвирлауны үз эченә ала, аңа инициатор карары буенча график һәм (яисә) таблицалы материаллар кушымта итеп бирелергә мөмкин.

### 3 статья. Халык мәнфәгатьләрендә инициативалы проектлар гамәлгә ашырыла ала торган территорияне билгеләү

1. Инициативалы проектлар тулаем Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, шулай ук түбәндәге территорияләрдәге халык мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) торак пункт;

2) торак пунктлар төркеме;

2. Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне (җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне) хәл итү һәм (яисә) Байлангар авыл башкарма комитеты карары белән (шул исәптән муниципаль программаны раслау турындагы карар белән) аерым муниципаль программаларның чараларын үтәү буенча инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Байлангар авыл җирлеге территориясен өлешләргә (округларга) бүлү каралырга мөмкин. Күрсәтелгән очракта инициативалы проектлар Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге территориясенең (округының) тиешле өлеше чикләрендә тәкъдим ителә, тикшерелә һәм гамәлгә ашырыла.

## Бүлек 2. **Инициативалы проектларны тәкъдим итү һәм тикшерү**

### 4 статья. Проект инициаторлары

1. Инициативалы проектны кертү инициативасы белән түбәндәгеләр чыгыш ясарга хокуклы:

1) уналты яшькә җиткән һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге территориясендә яшәүче кимендә ун[4] граждан булган инициатив төркем (алга таба – инициатив төркем);

2) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары;

3) авыл торак пунктының старостасы;

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затлар (алга таба – проект инициаторлары):

1) инициативалы проект әзерлиләр;

2) инициативалы проект буенча фикер алышуны оештыралар яисә әлеге бүлек нигезләмәләре нигезендә инициативалы проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклауны тәэмин итәләр;

3) инициатив проектны Байлангар авыл башкарма комитетына кертәләр;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуда катнашалар;

5) башка хокукларны гамәлгә ашыралар һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән һәм аның нигезендә кабул ителгән Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларны башкаралар.

3. Инициатив төркем төзү һәм аның тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәнең формасы Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан раслана.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарә органнары булып торучы проект инициаторлары тарафыннан кабул ителә.

5. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар иҗтимагый берләшмәләр булып торучы проект инициаторлары тарафыннан аларның гамәлгә кую документлары нигезендә кабул ителә.

**5 статья. Инициативалы проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнар фикерен ачыклау**

1. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру күздә тотыла торган Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкы яисә аның өлешенең халкы тарафыннан хупланырга тиеш.

2. Проектның инициаторы түбәндәге формаларда инициативалы проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклауны оештыра:

1) гражданнар җыенында инициативалы проектны карау;

2) гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә инициативалы проектны карау;

3) гражданнардан сорашып белешү үткәрү;

4) инициативалы проектны хуплап, гражданнарның имзаларын җыю.

3. Проектның инициаторы инициативалы проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклауның берничә төреннән файдалану турында карар кабул итәргә хокуклы.

**6 статья. Инициативалы проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы**

1. Инициативалы проектны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы (алга таба – җыелыш) проект инициаторы карары буенча билгеләнә һәм үткәрелә.

2. Җыелыш Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегенең анда яшәүчеләр мәнфәгатьләрендә инициативалы проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориясе өлешендә үткәрелә. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә планлаштырылса, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге территориясенең төрле өлешләрендә берничә җыелыш уздырылырга мөмкин.

3. Җыелышта уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

1) Җыелыш кара-каршы (очная) фикер алышу формасында уздырыла – көн тәртибе һәм тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен халыкның уртак катнашуы формасында;

4. Бер җыелышта берничә инициативалы проект каралырга мөмкин. Күрсәтелгән очракта җыелышны оештыру һәм уздыру буенча хокук һәм бурычлар проектлар инициаторлары тарафыннан бергә гамәлгә ашырыла.

5. Җыелыш үткәрү, документлар әзерләү һәм тарату чыгымнары өчен проект инициаторы җаваплы.

6. Байлангар авыл башкарма комитеты проект инициаторына җыелыш үткәрүдә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны үткәрү өчен түләүсез бина бирә. Байлангар авыл башкарма комитеты карары белән җыелышлар үткәрү өчен бирелә

торган биналарның исемлеге билгеләнергә мөмкин.

7. Катнашучылар саны 50 кешене тәшкил иткәндә җыелыш хокуклы дип санала.

**7 статья. Җыелышны үткәрүгә әзерлек**

1. Җыелышны уздыру турында проект инициаторы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) фикерләшү өчен җыелыш үткәрелә торган инициативалы проект;

2) җыелыш үткәрү формасы (кара-каршы фикер алышу-читтән торып (очно-заочно));

3) җыелышның көн тәртибе, ә җыелыш кара-каршы фикер алышу-читтән торып (очно-заочно) уздырылган очракта – халыкның тавыш бирүен уздыру планлаштырыла торган мәсьәләләр;

4) җыелыш уздыру датасы, вакыты, урыны, ә җыелыш кара-каршы фикер алышу-читтән торып (очно-заочно) уздырылган очракта – шулай ук тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча халыкның карарларын кабул итү тәмамлану датасы һәм мондый карарлар тапшырылырга тиешле урын яисә адрес, йә тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирү өчен махсуслаштырылган сайттан файдалану турында карар;

5) кара-каршы фикер алышу (очно) формасында үткәрелә торган җыелышта катнашучыларның яисә, җыелышны кара-каршы фикер алышу-читтән торып (очно-заочно) уздырган очракта, көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча кара-каршы фикер алышуда катнашучыларның фаразланган саны;

6) җыелыш үткәрелә торган территориядә яшәүчеләргә аны уздыру турында мәгълүмат бирү ысуллары;

2. Проектның инициаторы Байлангар авыл башкарма комитетына җыелыш үткәрү турында аны уздыру көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча язмача хәбәрнамә җибәрә.

3. Җыелышны уздыру турында хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) проект инициаторы турында белешмәләр (инициативалы төркем әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, аларның яшәү яисә булу урыны турында белешмәләр, авыл торак пункты старостасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, чараның башка инициаторы исеме һәм аның урнашкан урыны);

2) әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмәләр

3) проект инициаторларының җыелышны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә функцияләрен үтәргә вәкаләтле затлары фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, телефон номерлары.

4) җыелыш уздыруга ярдәм итү турында, шул исәптән җыелыш (җыелышны кара-каршы фикер алышу-читтән торып уздырган очракта кара-каршы фикер алышу) уздыру өчен урын бирү турында һәм (яисә) тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирү өчен махсуслаштырылган сайттан файдалану турында үтенеч;

4. Җыелышны уздыру турында хәбәрнамәгә проект инициаторы һәм проектның инициаторы аны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә бирү функцияләрен башкарырга вәкаләтле итеп билгеләгән затлар тарафыннан имза салына. Инициатив төркем исеменнән җыелыш үткәрү турында хәбәрнамәгә инициатив төркем тарафыннан аны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә функциясен үтәргә вәкаләтле итеп билгеләнгән затлар имза сала.

5. Җыелышны уздыру өчен урын бирү турында үтенеч булган очракта, Байлангар авыл башкарма комитеты хәбәр килгән көннән алып биш көн эчендә уздыру өчен урын бирү мөмкинлеге турында проект инициаторына хәбәр итә яисә җыелышны уздыру урынын һәм (яисә) датасын һәм вакытын үзгәртергә тәкъдим итә. Проектның инициаторы күрсәтелгән тәкъдимне алган көннән алып өч көн эчендә җыелышны (җыелышны кара-каршы фикер алышу-читтән торып уздырган очракта

кара-каршы фикер алышу) уздыру урынын һәм (яисә) датасын һәм вакытын үзгәртүгә ризалыгы яисә килешмәве турында хәбәр итәргә тиеш.

6. Байлангар авыл башкарма комитеты җыелыш үткәрү турында, шул исәптән инициативалы проект белән танышу тәртибе турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында яисә махсуслаштырылган сайтта белешмәләр урнаштыра:

1) хәбәрнамә кергән көннән алып өч көн эчендә җыелыш үткәрү турында;

2) җыелышны уздыру урынын һәм (яисә) датасын һәм вакытын үзгәртү турындагы тәкъдим белән проект инициаторы ризалыгын алганнан соң ике көннән дә соңга калмыйча (җыелыш кара-каршы фикер алышу-читтән торып уздырылган очракта, кара-каршы фикер алышу).

7. Байлангар авыл башкарма комитеты проект инициаторына җыелыш үткәрүдә ярдәм итү максатларында вәкаләтле вәкил билгеләп куярга хокуклы. Байлангар авыл башкарма комитеты вәкаләтле вәкилне билгеләп кую турында алдан ук проект инициаторына хәбәр итә.

**8 статья. Җыелышны кара-каршы фикер алышу (очно) формасында уздыру тәртибе**

1. Җыелыш башланганчы, проект инициаторы җыелышта катнашкан гражданнарны Байлангар авыл башкарма комитеты раслаган форма буенча исемлек төзеп теркәүне тәэмин итә. Җыелышта катнашкан гражданнар исемлеге җыелыш беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

2. Җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү тәртибе җыелышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән раслана. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча карарлар җыелышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3. Җыелыш проект инициаторы вәкиле тарафыннан ачыла. Җыелышны алып бару өчен рәис һәм секретарь сайлана.

4. Рәис җыелышны алып бара, көн тәртибендәге мәсьәләләрне игълан итә, катнашучыларга чыгыш ясау өчен сүз бирә, җыелышта кабул ителгән карарларны формалаштыра, аларны тавыш бирүгә куя, тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә.

5. Секретарь җыелыш беркетмәсен алып бара, анда җыелыш кабул иткән барлык карарлар чагылдырыла, алар буенча тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелә. Җыелыш беркетмәсенә секретарь һәм җыелыш рәисе имза сала.

6. Җыелыш беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) җыелышны уздыру урыны һәм вакыты;

2) җыелышта катнашкан гражданнар саны;

3) яшәү урынын күрсәтеп, җыелыш рәисе һәм секретаре турында белешмәләр;

4) җыелышның көн тәртибе, чыгышларның эчтәлеге;

5) көн тәртибендәге сораулар буенча кабул ителгән карарлар

**9 статья. Инициативалы проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе үткәрү**

1. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориядә 16 яшькә җиткән яшәүчеләрнең саны 1000 кешедән артып киткән очракта, инициативалы проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе (алга таба – конференция) уздырылырга мөмкин.

2. Конференция, әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, әлеге Тәртипнең 7-10 статьяларында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 8 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләмәләр

белән беррәттән конференция үткәрү турында проект инициаторы карарында түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) делегацияләрне сайлау вәкиллеге нормасы, ул территориянең 16 яшькә җиткән 100 кешесенә 1 делегаттан ким була алмый;

2) делегатларны сайлау өчен җыелышлар уздыру сроклары һәм тәртибе.

4. Конференция беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып делегатларны сайлау турында җыелыш беркетмәләре тора.

## 10 статья. Инициативалы проектларга ярдәм йөзеннән гражданнар имзаларын җыю

Инициативалы проектларны хуплап гражданнар имзаларын җыю (алга таба – имзалар җыю) проект инициаторы тарафыннан үткәрелә.

Инициативалы проектларны хуплап имзалар саны, инициатив төркем әгъзаларының имзаларын да кертеп, кимендә егерме биш кеше булырга тиеш.

Имзалар түбәндәге тәртиптә җыела:

1) имзалар аларны имза кәгазенә кертү юлы белән җыела, аның формасы Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан раслана;

2) имзалар кәгазендә имзалар җыю гамәлгә ашырыла торган инициативалы проект күрсәтелә;

3) имзалар кәгазендә кешенең имзасы һәм аны кую датасы куела. Имза һәм аны кую датасын кеше үз кулы белән куя. Имзалар кәгазендә үз имзасын куйган кеше турындагы белешмәләр имзалар кәгазенә аның үтенече буенча имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән белешмәләр бары тик кулдан язу ысулы белән генә кертелә, шул ук вакытта карандашлар куллану рөхсәт ителми;

4) кеше **бер үк** инициативалы проектны хуплап бер генә тапкыр имза куярга хокуклы;

5) һәр имзалар кәгазе имзалар җыюны гамәлгә ашыручы проект инициаторының имзалары белән таныкланырга тиеш. Имзалар кәгазен таныклаганда, имзалар җыюны башкарган проект инициаторы вәкиле үз кулы белән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын күрсәтә, шулай ук имзасын һәм аны кую датасын күрсәтә;

6) Имзалар җыйганда, имза кәгазенең алгы ягын һәм арткы ягын тутыру рөхсәт ителә. Шул ук вакытта арткы як имзаларның бердәм нумерациясе белән алгы якның дәвамы булып тора, ә таныклау имзалары һәм имзалар җыюны гамәлгә ашыручы проект инициаторы вәкиле турында белешмәләр имза кәгазенең арткы ягына соңгы имзадан соң ук куела;

7) Имзалар җыйганда һәр кешенең «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы алынырга тиеш.

## 11 статья. Әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында аларның фикерен ачыклау өчен гражданнардан сораштыру үткәрү

1. Инициативалы проектны Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә тулаем гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән очракта әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерләрен ачыклау өчен, гражданнардан Байлангар авыл җирлеге халкы яисә инициативалы проект тормышка ашырылырга тәкъдим ителә торган аның **өлеше** инициативасы белән сораштыру (алга таба – сораштыру) уздырыла.

1. Сораштыруны билгеләү өчен проект инициаторы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Советына гариза җибәрә, анда түбәндәгеләр

күрсәтелә:

1) сораштыру уздыру тәкъдим ителә торган инициативалы проект;

2) проект инициаторы тәкъдимнәре:

ә) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары турында;

б) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формалаштыру турында;

в) сораштыру үткәрү методикасы турында;

г) сораштыруда катнашучы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә яшәүчеләрнең минималь саны турында;

3) проект инициаторы турында белешмәләр (инициатив төркем әгъзаларының фамилиясе, исемнәре, атасының исеме, аларның яшәү яисә булу урыны турында белешмәләр, авыл торак пункты старостасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, чараның башка инициаторы исеме һәм аның урнашкан урыны).

2. Әгәр проектның инициаторы инициатив төркем булса, гариза инициатив төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Әгәр проектның инициаторы әлеге Тәртипнең 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булса, гариза проект инициаторының вәкаләтле заты һәм Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге яисә инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган аның өлешенең кимендә 10 кешесе тарафыннан имзалана. Бу очракта гаризада шулай ук гаризаны имзалаган затлар турында белешмәләр (фамилияләре, исемнәре, әтисенең исеме, аларның яшәү яки булу урыны турында белешмәләр) күрсәтелә.

3. Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Советы гариза кергән көннән алып кимендә 30 көндә аны карый һәм сорашып белешүне билгеләү яисә сорашып белешүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4. Әгәр җибәрелгән хокук бозулар инициативаны тәкъдим итүдә катнашкан Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге халкының ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөреслек белән билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, әлеге статьяда билгеләнгән сораштыру уздыру турындагы инициативаны тәкъдим итү тәртибен бозу сораштыру үткәрүдән баш тартуга нигез була.

5. Инициативалы проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнардан сорашып белешү «Кукмара муниципаль районы Байлангар авылы җирлегендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 08 сентябрендәге 22 номерлы Байлангар авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

6. Сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендәге 16 яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

7. Байлангар авыл башкарма комитеты сораштыру нәтиҗәләрен проект инициаторына нәтиҗә чыгарганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча җиткерә.

## Бүлек 3. **Инициативалы проектларны кертү һәм карау**

### 12 статья. Инициативалы проектларны кертү

1. Инициативалы проектны Байлангар авыл башкарма комитетына керткәндә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) проектның кәгазь чыганактагы һәм электрон рәвештә график **һәм** (яисә) таблица материаллары кушымта итеп бирелергә мөмкин булган тасвирламасы;

2) инициатив төркем төзү беркетмәсе яисә әлеге Нигезләмәнең 4 статьясындагы 4, 5 өлешләре нигезендә башка документлар, шулай ук инициативалы проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда аның исеменнән Байлангар авыл башкарма комитеты белән хезмәттәшлек итәргә вәкаләтле затларны билгеләү турында проект инициаторының карары;

3) гражданнар җыелышы яисә конференциясе беркетмәсе, гражданнардан сораштыру нәтиҗәләре һәм (яисә) муниципаль берәмлек халкының яисә аның өлешенең инициативалы проектка ярдәм күрсәтүен раслый торган имзалар кәгазьләре.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар инициативалы проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда, проектның инициаторы тарафыннан турыдан-туры Байлангар авыл башкарма комитеты белән хезмәттәшлек итәргә билгеләнгән вәкаләтле зат тарафыннан нил авыл башкарма комитетына тапшырыла яисә аны җибәргәндә бәясен билгеләп һәм эчендәге әйберләре исемлеге белән почта аша җибәрелә.

3. Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документларны алу көне проектны кертү датасы булып тора.

4. Байлангар авыл башкарма комитетына документлар инициативалы проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда Байлангар авыл башкарма комитеты белән турыдан-туры эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылган очракта, күрсәтелгән затка исемлекне һәм Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан аларны алу датасын күрсәтеп, документлар алу турында расписка бирелә. Расписка Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан документларны алган көнне бирелергә тиеш.

## 13 статья. Инициативалы проектларны карау комиссиясе

1. Инициативалы проектларны карау комиссиясе (алга таба – комиссия) инициативалы проектларның социаль-икътисадый әһәмиятен объектив бәяләү һәм аларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру максатларында төзелә.

2. Комиссия саны 6 кеше тәшкил итә.

3. Комиссиянең персональ составы Байлангар авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән билгеләнә. Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысы Байлангар авыл җирлеге Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнә. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясарга мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген булдырмыйча төзелә.

4. Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, комиссия секретаре һәм комиссия эшендә шәхсән катнашучы комиссия әгъзаларыннан тора.

5. Комиссия рәисе:

1) комиссия эшен оештыра, аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

2) комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибе проектын формалаштыра;

3) комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

4) комиссия утырышларында рәислек итә.

6. Комиссия рәисе урынбасары комиссия рәисе вакытлыча булмаган очракта аның вазыйфаларын башкара.

7. Комиссия секретаре:

1) комиссия эшчәнлеген мәгълүмати һәм документлар белән тәэмин итә, шул исәптән комиссия утырышына әзерлекне дә тәэмин итә;

3) комиссия әгъзаларына, комиссия утырышына чакырылган проектлар инициаторларына һәм башка затларга комиссиянең чираттагы утырышын уздыру датасы, урыны һәм комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибе турында хәбәр итә;

3) комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара.

8. Комиссия әгъзасы:

1) комиссия эшендә, шул исәптән комиссия утырышларында катнаша;

2) комиссия эше мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертә;

3) комиссия утырышларында карала торган документлар һәм

материаллар белән танышу;

4) комиссия утырышында катнашучыларга сораулар бирә;
5) комиссия утырышларында тавыш бирә.

9. Комиссия эшенең төп формасы утырышлар була.

10. Комиссия утырышы анда комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булу шартыларында хокуклы дип санала.

11. Проектның инициаторларына һәм аларның вәкилләренә комиссия тарафыннан инициативалы проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителә. Инициативалы проектны карау планлаштырыла торган комиссия утырышы турында проект инициаторларына аны үткәрү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

12. Проект буенча фикер алышу һәм комиссия тарафыннан карарлар кабул итү проект инициаторы һәм чакырылган башка затлар катнашыннан башка башкарыла.

13. Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзалары саныннан гади күпчелек ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия әгъзалары карарлар кабул итү турындагы мәсьәләләр буенча фикер алышканда бертигез хокукларга ия.

15. Комиссия кабул иткән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язмача бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә кушып бирелергә тиеш.

16. Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, аңа комиссия утырышында рәислек итүче, комиссия секретаре һәм комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан комиссия утырышы уздырылганнан соң өч эш көне эчендә имза салына.

Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсенә имза салынган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча аны Байлангар авыл башкарма комитеты Җитәкчесенә җибәрә.

18. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Байлангар авыл башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

### 14 статья. Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан инициативалы проектны карау тәртибе

1. Инициативалы проект Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан аны керткән көннән соң 30 көн эчендә карала.

2. Инициативалы проектны Байлангар авыл башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат инициативалы проект Байлангар авыл башкарма комитетына кертелгән көннән соң өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш һәм әлеге Тәртипнең 2 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләр булырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга Байлангар авыл башкарма комитетына инициативалы проект буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен тапшыру мөмкинлеге турында, аларны тәкъдим итү вакытын күрсәтеп, мәгълүмат бирелә.

3. Инициативалы проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тәкъдим итү срогы җиде эш көне тәшкил итә. Үзләренең күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен Кукмара муниципаль районының Яңыльский авыл җирлегендә яшәүче 16 яшькә җиткән халкы җибәрергә хокуклы. Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр Байлангар авыл башкарма комитетына шәхсән турыдан-туры тапшырыла яисә почта аша яки махсуслаштырылган сайтта форманы тутыру юлы белән җибәрелә.

4. Инициативалы проект буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерүне комиссия гамәлгә ашыра.

5. Инициативалы проектны карау нәтиҗәләре буенча комиссия Байлангар авыл

җирлеге башлыгына әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән карарларның берсен кабул итәргә тәкъдим итә. Комиссия карарында шулай ук проектны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр булырга мөмкин.

Байлангар авыл башкарма комитетына берничә, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап, инициативалы проект кертелгән очракта, комиссия Байлангар авыл җирлеге башлыгына конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүне оештырырга киңәш итә.

6. Конкурс нигезендә сайлап алу әлеге Тәртипнең 15 статьясы нигезендә оештырыла. Конкурс нәтиҗәсендә сайлап алуны үткәрү турындагы хәбәр проектлар инициаторларына тиешле карар кабул ителгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7. Комиссия киңәшен исәпкә алып яисә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча Байлангар авыл җирлеге башлыгы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициативалы проектны хупларга һәм инициативалы проектны хупларга һәм аның өстендә эшне Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты турындагы карар белән каралган максатларга бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм (яисә) Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты проектын төзү һәм карау (Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү) тәртибе нигезендә эшне дәвам итәргә;

2) инициативалы проектны хуплаудан баш тартырга һәм, инициативалы проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кайтарырга.

8. Байлангар авыл җирлеге башлыгы түбәндәге очракларның берсендә инициативалы проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициативалы проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициативалы проектның Россия Федерациясенең федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләренә, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) формалаштыру чыганагы булып инициатив түләүләр тормый торган инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты акчалары булмау;

5) инициативалы проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

9. Проектны карау нәтиҗәләре буенча карар проект инициаторына кабул ителгән көненнән соң өч көннән дә соңга калмыйча проект инициаторына җибәрелә.

10. Байлангар авыл башкарма комитеты проект инициаторларына бергәләп инициативалы проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә хокуклы, ә әлеге статьяның 8 өлешендәге 5 пунктында каралган очракта, тәкъдим итәргә бурычлы, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы карамагына аларның компетенцияләре нигезендә карарга тәкъдим итәргә тиеш. Проектны эшләп бетерү өчен, комиссия әгъзалары, Байлангар авыл башкарма комитеты вәкилләре, проект инициаторы вәкилләре арасыннан эшче төркем төзи, шулай ук проектны эшләп бетерү срогын билгели. Эшләп бетерелгән инициативалы проект Комиссия тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 статьясы һәм әлеге статья нигезендә карала.

## 15 статья. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу

1. Конкурс нигезендә сайлап алуны комиссия гамәлгә ашыра.
2. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:
1) инициативалы проект хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманы ачыклауда һәм аны гамәлгә ашыруда халыкның катнашу дәрәҗәсе;
2) инициатив проектны гамәлгә ашырудан социаль нәтиҗәлелек;
3) Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары, аларның кыйммәте, аларга тиешле баллар һәм үлчәм коэффициентлары (алга таба – критерийлар) әлеге Тәртипкә кушымтада билгеләнгән.
3. Конкурс нигезендә сайлап алу әлеге Тәртипнең 15 статьясы нигезендә үткәрелә торган комиссия утырышында гамәлгә ашырыла.
4. Комиссия конкурс сайлавы узган инициативалы проектларны ачыклау критерийлары нигезендә инициативалы проектларны бәяли
5. Конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча, комиссия критерийлары нигезендә йомгаклау билгесен исәпкә алып, комиссия инициативалы проектларны конкурс сайлавын узган яисә узмаган дип игълан итү турында карарлар кабул итә.
6. Конкурс нигезендә сайлап алуны узган дип барлык критерийлар буенча максималь суммар балл алган инициативалы проект (ике, өч инициативалы проект һ.б.) игълан ителә.

## 16 статья. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру турында Байлангар авыл башкарма комитеты карары

1. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру турында Байлангар авыл башкарма комитеты Җитәкчесе карар чыгара.
2. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру турындагы карарда түбәндәгеләр булырга тиеш:
1) инициатив проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә (адресын яисә урынын күрсәтеп) төзелергә тиешле объектның исеме яисә инициатив проект гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараның исеме;
2) Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты акчаларын тоту юнәлеше (төзелеш реконструкция, сатып алу, чара (чаралар) уздыру, башкасы);
3) инициативалы проектны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш бүлүчесе исеме;
4) заказчы, төзүче исеме;
5) объектны файдалануга тапшыру (сатып алу), чараны (чараларны) гамәлгә ашыру срогы;
6) инициатив түләүләр күләме бүлеп, объектның фаразланган (чикле) бәясе яисә чараны (чараларны) уздыруга акчаларның иң чик күләме;
7) инициатив түләүләр күләмен күрсәтеп, объектның күздә тотыла торган (иң чик) бәясен яисә чараны (чараларны) уздыруга акчаларның иң чик күләмен гамәлгә ашыру еллары буенча бүлү.

## 17 статья. «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә инициативалы проект турында мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм урнаштыру тәртибе

1. Инициативалы проектны Байлангар авыл башкарма комитеты тарафыннан карау турында, инициативалы проектны гамәлгә ашыру барышы турында, шул исәптән акчаларны файдалану, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның

мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында басылып чыгарга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

2. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында Башкарма комитет отчеты Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә урнаштырылырга тиеш.

Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, тикшерү һәм карау Тәртибенә КУШЫМТА

Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу КРИТЕРИЙЛАРЫ, аларның кыйммәте, аларга тиешле баллар һәм үлчәм коэффициентлары

| № т/б | Исеме конкурс нигезендә.... сайлап алу критерие | Конкурс нигезендә сайлап алу критерие билгеләре | Баллар саны | Үлчәм коэффициенты |
|---|---|---|---|---|
| **1.** | *(критерийлар төркеменең исеме күрсәтелә)* | | | |
| 1.1. | *(критерийның исеме күрсәтелә)* | *(критерийның кыйммәте күрсәтелә)* | *(критерийның тиешле кыйммәтенә ирешкәндә бирелә торган баллар саны күрсәтелә)* | *(күрсәтелә....) весовой коэффициент в долях от единицы в зависимости от значимости критерия, сумма всех весовых коэффициентов должна составлять единицу)* |
| | | *(критерийның кыйммәте күрсәтелә)* | 90 балл | |
| | | *(критерийның кыйммәте күрсәтелә)* | 80 балл | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |